
# 22 июнь 1941 ел

# Дәһшәтле 1418 көн



# СУГЫШ ЧОРЫ ГЕРОЙ-ШӘҺӘРЛӘРЕ



# ГЕРОЙ-ШӘҺӘРЛӘР

ЛЕНИНГРАД



СЕВАСТОПОЛЬ



СТАЛИНГРАД



КЕРЧЬ



МИНСК



НОВОРОССИЙСК




МӘСКӘҮ



ТУЛА



БРЕСТ



МУРМАНСК



ОДЕССА



СМОЛЕНСК



КИЕВ



# ЛЕНИНГРАД



"Алтын йолдыз" медале

Ленинград шәһәренә Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары өчен «Герой-шәһәр» исеме бирелә һәм «Алтын йолдыз» медале тапшырыла.
Шәһәр 900 көн блокадада торды.

Исемсез калкулык





Ленинградны саклаучы батырларга


# СМОЛЕНСК



Смоленск сугышы 1941 елның 10 июленнән 10 сентябренә кадәр дәвам итә. Шуның нәтиҗәсендә дошманның Мәскәүне «Яшен тизлеге» белән алам дигән планы өзелә.
1985 елда Смоленскка «Герой-шәһәр» исеме бирелә.



Смоленскны яклаучы батырларга һәйкәл.



# СОРАУ-ҖАВАП

- Бөек Ватан сугышы кайчан башлана?
- Ул ничә ел һәм ничә көн  дәвам итә?
- Ничә герой-шәһәр бар?
- Кемнәр алар герой пионерлар?
- Советлар Союзы герое исеме алган пионерлар ничәү һәм кемнәр алар?
- Советлар Союзы геройларыннан безнең якташлар?
- Кемнәрне без Җәлилчеләр дип атыйбыз, алар ничәү?
- Безнең авылдан ничә кеше сугышка китә һәм ничәсе исән кайта?
- Нинди сугыш чоры җырлары беләсез?
- Бүгенгесе көндә авылыбызда ничә ветеран бар?

# МОСКВА



Кремль



**Гитлерчылар Мәскәүне алуга беренче дәрәҗә әһәмият биреп, анда күп көч туплый, Мәскәү янында бөек сугыш башлана. Андагы каты сугышлар дошманны хәлдән тайдырып, көчсезләндерә һәм башкаладан чигенергә мәҗбүр итә. Мәскәү янындагы тарихи җиңү фашист яуларын тар-мар итүнең башлануы була.**



**Мәскәү астында сугыш 7 айга якын, 203 көн һәм төн бара. (1941 елның 30 сентябреннән 1942 елның 20 апреленә кадәр).**



Мәңгелек ут

# КУРСК ДУГАСЫ



Танкистларга һәйкәл

Курск дугасындагы сугыш 17 ай дәвам итә. 2007 елның 27апрелендә Курск шәһәренә “Хәрби дан шәһәре” почетлы исеме бирелә.



Курск сугышы батырларына



"Утлы дуга"
музей һәм күргәзмәсе



Авылдашыбыз Сибгат Хәким 1942елның июленнән 1943 елныңфевраленә кадәр барысы 7 ай Курск сугышында катнаша. Ялкынлы шигырьләрен язуны да туктатмый.

# ТУЛА





**Дәһшәтле сугыш елларында дошман шәһәргә үтеп керә алмады: нык торды 1976 елда Тула халкының батырлыгы һәм фидакарьлеге өчен Тула шәһәренә “Герой шәһәр исеме бирелә.**





Туланы яклаучыларга һәйкәл


# СТАЛИНГРАД

**Мамай курганы - Сталинград сугышы батырларына куелган тарихи-мемориаль комплекс**



**Мамай курганы**

**1943 елның 2 февралендә Мамай курганы тирәсендә, Сталинград сугышы тәмамлана**



**Су композициясе**



Арча районы егете Сафиуллин Гани Биккенә улы 38 нче укчы дивизиянең командиры булып Сталинград сугышында катнаша. Алар18 меңләп дошманны пленга төшерәләр һәм генерал-майор исеменә лаек була

# МУРМАНСК



**Фашист Германиясе 3 көн өчендә Мурманск шәһәрен басып алырга уйлый. Ләкин дошманнарның планы өзелә.**

**1985 елда Мурманск шәһәренә "Герой-шәһәр» дигән югары исем бирелә.**



Анатолий Бредов һәйкәле



# МИНСК




**Өч еллык басып алыну вакытында Минск шәһәре һәм авылларыннан немецлар 400 меңгә якын кешене үтерәләр, ә шәһәрнең үзен җимерек хәленә төшерәләр. Ләкин Минск бирелми.**

**1974 елда Минск «Герой-шәһәр» исеме ала.**

"Минск- Герой-шәһәр" архитектура комплексы






# КИЕВ



**Украина башкаласы немец илбасарлары тарафыннан 778 көн буена оккупацияләнеп тора. Киев, фашистларның сайланма гаскәре ударларын кире кагып, дошманның алга баруын ике айдан артыгракка тоткарлады. Шушы батырлыгы өчен Киевка «Герой-шәһәр» исеме бирелә.**



"Бөек Ватан сугышы тарихы" милли музее



# КЕРЧЬ



Керчь шәһәре 1944 елның 11 апрелендә азат ителә.

1975 елда Бөек Ватан сугышындагы батырлыгы һәм кыюлыгы өчен Керчь шәһәренә

«Герой-шәһәр» исеме бирелә.



Аджимушкай мемориалы




# НОВОРОССИЙСК



Новороссийск, дошманны Кавказга җибәрмәс өчен, батырларча көрәшә. Көрәштәге батырлыгы һәм кыюлыгы өчен аңа «Герой-шәһәр» исеме бирелә. Дошман тоткынлыгыннан азат ителгән көн – 16 сентябрь 1943 ел - традиция буенча шәһәрнең туган көне булып бәйрәм ителә





# 9 май 1945 ел
# Бөек Җиңү көне

Төзеде: Гайнетдинова Гөлназ
Сәлихҗан кызы
(8 сыйныф җитәкчесе)